Республика Татарстан
Исполнительный комитет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

08.12.2025 Менделеевск ш. № 782

«Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм җибәрү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карарын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 10 августындагы 480 нче номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм җибәрү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентынының 1.1. пунктын (мөрәҗәгать итүчеләр даирәсен) үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Муниципаль хезмәт алуга баланың ата-анасы (законлы вәкиле) гариза бирүче булып тора (алга таба - мөрәҗәгать итүче).

1.2. “Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр (функцияләр) порталы” федераль дәүләт мәгълүмат системасы (https://www.gosuslugi.ru/) һәм/яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) төбәк порталлары федераль дәүләт мәгълүмат системасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмати системаларның мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы” федераль дәүләт мәгълүмат системасында теркәү процедурасын узуны тәгәлләгән баланың ата-анасы (законлы вәкиле) муниципаль хезмәт күрсәтүләргә гариза бирүче булып тора.

1.3. Мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (алга таба - оешма) чираттан тыш урнашу хокукына ия:

судьяларның балалары;
Россия Федерациясе прокурорларының һәм Тикшерү комитеты хезмәткәрләренең балалары;
Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарның һәм аларга тиңләштерелгән гражданнар категорияләренең балалары;
Россия Федерациясенең Төньяк Кавказ төбәге территориясендә террорчылык оешмаларын һәм төркемнәрен ачыклау һәм аларның эшчәнлеген туктату буенча махсус көчләрнең, гаскәрләрнең (көчләрнең) берләштерелгән төркемнәренең һәлак булган (хәбәрсез югалган), вафат булган, инвалид калган хезмәткәрләренең һәм хәрби хезмәткәрләренең балалары;
Дагыстан Республикасы территориясендә террорчылыкка каршы көрәштә турыдан-туры катнашкан һәм һәлак булган (хәбәрсез югалган), үлгән, хезмәт бурычларын үтәү белән бәйле рәвештә инвалид булган хәрби хезмәткәрләрнең һәм эчке эшләр органнары, дәүләт янгынга каршы хезмәте, җинаять-башкарма системасы хезмәткәрләренең балалары".
Оешмага беренче чиратта урнашу хокукына ия:
инвалид балалар һәм ата-аналарының берсе инвалид булган балалар;
күп балалы гаиләләрдәге балалар;
полиция хезмәткәренең балалары, шул исәптән хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә гариплек яисә сәламәтлеккә башка төрле зыян килү нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) полиция хезмәткәренең балалары; полициядә хезмәт итү чорында алган авыру аркасында вафат булган полиция хезмәткәренең балалары; хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә гариплек яисә сәламәтлеккә башка төрле зыян килү аркасында полиция хезмәтеннән азат ителгән Россия Федерациясе гражданының балалары һәм алга таба полициядә хезмәт итү мөмкинлеген кире какканнар; хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә алган гариплек яисә сәламәтлеккә башка төрле зыян килү нәтиҗәсендә йә полициядә хезмәт итү чорында алган, алга таба полициядә хезмәт итү мөмкинлеген юкка чыгарган авыру нәтиҗәсендә полициядә хезмәттән азат ителгәннән соң бер ел эчендә вафат булган Россия Федерациясе гражданының балалары; полиция хезмәткәре, Россия Федерациясе гражданы карамагындагы (булган) балалар;
хәрби хезмәткәрләрнең балалары;
махсус исемнәре булган һәм җинаять-үтәтү системасы учреждениеләрендә һәм органнарында, дәүләт янгынга каршы хезмәтенең Федераль янгынга каршы хезмәтендә, Россия Федерациясе таможня органнарында хезмәт итүче хезмәткәрләрнең, шул исәптән хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә алган гариплек яисә сәламәтлеккә башка төрле зыян килү нәтиҗәсендә һәлак булганнарның (вафат булганнарның); хезмәтне узган чорда алган авыру нәтиҗәсендә вафат булганнарның балалары; хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә алган гариплек яисә сәламәтлегенә бүтән төрле зыян килү нәтиҗәсендә хезмәттән азат ителгән һәм алга таба хезмәтне узу мөмкинлегеннән мәхрүм ителгән; хезмәт вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә алган гариплек яисә сәламәтлегенә башка төрле зыян килү аркасында хезмәттән азат ителгәннән соң бер ел эчендә йә хезмәтне узу чорында алган, алга таба хезмәтне узу мөмкинлегеннән

мәхрүм иткән авыру аркасында вафат булган; Россия Федерациясе гражданы хезмәткәре карамагында булганнар".

2. Әлеге карарны интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: https://mendeleevsk.tatarstan/ru һәм интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы"нда түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ю. М. Рыбаковага йөкләргә.

Җитәкче А.Ф.Искаков